| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА МАМЫКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МАМЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Мамык ав. КАРАР

«11» ноябрь 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мамык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Тельман ур., 51а йорты адресы буенча «Нефтьче» авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Тельман, Октябрь, Крупская, Буденный, Яшьләр, Куйбышев, Кызылармия, Ворошилов, Пионер, Елга, Киров тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ьыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 28 ноябрендә сәгать 10 сәг.00 минутта Мамык авылы Гоголь урамы, 10 йорт адресы буенча Мамык урманчылыгы бинасы янында Мамык авыл җирлеге Мамык авылында Гоголь, Совет, Пушкин, Мичурин, Урманасты, Чапаев урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 28 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Мамык авылының Заречный тыкрыгы буенча 14нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Елга арьягы, Нефтьчеләр, Евгений Грунис, Елга арьягы тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2021 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Мамык авылының Күл яны урамы буенча 5 нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Подстанция, Күл Яны, Күл Яны тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Мамык авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү:

- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков